РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2026 Кукмара ш. № 166

Кукмара муниципаль районы буенча Россия ЭЭМ ның Кукмара муниципаль районы бүлегенең белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче балалары булган кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләренә (сержантлары, старшиналары, прапорщиклары) ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында

Кукмара муниципаль районы буенча Россия ЭЭМ ның Кукмара муниципаль районы бүлегенең белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче балалары булган кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләренә (сержантлары, старшиналары, прапорщиклары) ярдәм итү максатларында, «Россия Федерациясендә белем бирү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясы, Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 47 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Кукмара муниципаль районы буенча Россия ЭЭМ ның Кукмара муниципаль районы бүлегенең белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче балалары булган кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләре (сержантлары, старшиналары, прапорщиклары) гаиләләренә ярдәм итүнең түбәндәге өстәмә чараларын билгеләргә:

1.1. Ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) – Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара муниципаль районы буенча бүлегенең белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирү программаларын үзләштерүче балалары булган кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләреннән (сержантлардан, старшиналардан, прапорщиклардан) алына торган карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итәргә.

2. Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

2.1. баланы караган һәм тәрбияләгән өчен түләүдән азат итү турында ата-аналардан (законлы вәкилдән), туу турында таныклык күчермәсе һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара муниципаль районы бүлегеннән буенча раслый торган документны теркәп, гаризалар кабул итү эшен оештырырга.

3. Кукмара муниципаль районы буенча Россия ЭЭМ ның Кукмара муниципаль районы бүлегенең белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче балалары булган кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләренә (сержантлары, старшиналары, прапорщиклары) өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

4. Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегенең Финанс-бюджет палатасына белем бирү учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә каралган акчаларны үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**

Татарстан Республикасы Кукмара
муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесенең 19.03.2026 елның 166
номерлы карарына кушымта

Кукмара муниципаль районы буенча Россия ЭЭМ ның Кукмара муниципаль районы бүлегенең белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче балалары булган кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләренә (сержантлары, старшиналары, прапорщиклары) өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмә

1. Әлеге Кукмара муниципаль районы буенча Россия ЭЭМ ның Кукмара муниципаль районы бүлегенең белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче балалары булган кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләренә (сержантлары, старшиналары, прапорщиклары) ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 47 статьясы нигезендә Кукмара муниципаль районы буенча Россия ЭЭМ ның Кукмара муниципаль районы бүлегенең белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче балалары булган кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләре (сержантлары, старшиналары, прапорщиклары) гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү максатында эшләнгән.

2. Өстәмә ярдәм чарасы Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара муниципаль районы буенча бүлегенең кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләренең (сержантлар, старшиналар, прапорщиклар) балалары өчен билгеләнә

- Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче тәрбияләнүчеләргә.

3. Балаларга адреслы ярдәм тәрбияләнүчеләрнең ата-анасының (законлы вәкиленең) муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчаларына) һәм Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләренә йөрүче балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен түләүдән азат итүгә гаризасы һәм һәм әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә, белем бирү учреждениеләренең расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмалары җитәкчесе түбәндәгеләрне тәэмин итә:

4.1. түбәндәге исемлек нигезендә ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) документлар кабул итү эшен оештыруны:

а) баланы караган һәм тәрбияләгән өчен түләүдән азат итүгә гариза;

б) баланың туу турында таныклыгы реквизитлары;

в) ата-ананың (законлы вәкилнең) эш урыныннан белешмә.

4.2. гаризаны карау нәтиҗәләре буенча документларны тапшырган көннән алып 5 эш көне эчендә әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән балалар категориясендәге балаларны караган һәм тшрбияләгән өчен түләүләрдән азат итү турында боерык чыгаруны.

4.3. әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 пунктларын куллану өчен, ата-аналар биргән гаризаларны һәр 6 ай саен мониторинглауны.

5. Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләренә йөрүче тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары (законлы вәкилләре) түбәндәгеләрне башкара:

5.1. Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада каралган форма буенча өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү турында гаризалар җибәрәләр;

5.2. Гаризада күрсәтелгән тапшырылган документларның дөреслеге өчен тулы җаваплылык тоталар;

5.3. Бала караган һәм тәрбияләгән өчен түләүдән азат итү рәвешендә өстәмә ярдәм чарасы күрсәтелә торган категория үзгәргән очракта, белем бирү учреждениесе җитәкчесенә үз вакытында хәбәр итәргә һәм бала караган һәм тәрбияләгән өчен түләүне яңартуга гаризаны әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә җибәрергә.

6. Ярдәм чаралары күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

6.1. гариза бирүче Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара муниципаль районы буенча бүлегенең кече җитәкчеләр составы хезмәткәре (сержантлар, старшиналар, прапорщиклар) булып тормый;

6.2. әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында санап үтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

6.3. әлеге Нигезләмәнең 4.1 пункты нигезендә тапшырылган документлардагы белешмәләрнең дөрес булмавы фактын билгеләү.

7. Гариза бирүчегә ярдәм чаралары күрсәтү турында карар кабул итү өчен нигез булган дөрес булмаган белешмәләр бирү факты ачыкланган очракта, нигезсез алынган түләү гариза бирүче тарафыннан дөрес булмаган белешмәләр бирелгән көннән алып 10 көн эчендә Кукмара муниципаль районы бюджетына кайтарыла.

Гариза бирүче күрсәтелгән акчаларны ирекле кайтарудан баш тарткан очракта, алар суд тәртибендә түләтелергә тиеш.

8. Кукмара муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы барлык белем бирү учреждениеләре Әлеге Нигезләмәгә таяна.

Кукмара муниципаль районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенең Кукмара муниципаль районы белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче балалары булган кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләренә (сержантлары, старшиналары, прапорщиклары) өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турында нигезләмәгә 1 нче кушымта

Җитәкчегә ________________________________
(муниципаль белем бирү оешмасының исеме)

_____________________________________________

кемнән
____________________________________________
тәрбияләнүченең ата-анасының (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

_____________________________________________

чынлыкта яшәү адресы: ______________________
_____________________________________________
_____________________________________________

гариза.

____________________________________________________________________________________
(тәрбияләнүченең законлы вәкиленең ФИА),

баланың, минем улымның (кызымның, тәрбияләнүченең) законлы вәкиле (атасы, анасы)

__________________________________________________________________________________,
(тәрбияләнүченең ФИА)

_________________________________________________________________________________

булам, ____________________________________________ _эшлим.

_____________

Сездән _____________________

______________________________________________________________________________________
(белем бирү учреждениесенең исеме, төркем)

йөрүче баланы караган һәм тәрбияләгән өчен түләүдән азат итүегезне/түләүне яңартуны сорыйм.

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2026 елның ____ ______________ _____ номерлы карары нигезендә. «Кукмара муниципаль районы буенча Россия ЭЭМ бүлегенең Кукмара муниципаль районы белем бирү оешмаларында мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын үзләштерүче балалары булган кече җитәкчеләр составы хезмәткәрләренә (сержантлары, старшиналары, прапорщиклары) ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында»

_______________ _________________________________
(дата) имза/Фамилия ИА

Гаризага теркәлә:

1. Баланың туу турында таныклыгы күчермәсе;
2. Эш урыныннан белешмә.